**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге составына керүче Сосновый Бор поселогында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

13 ноябрь 2024ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 13 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2025 елда яшәү урыны буенча Кнәз авыл җирлеге Сосновый Бор поселогы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яштәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ("Сосновый Бор бистәсендә бистә эчендәге асфальт һәм вак таш белән эшләнгән юлларны ремонтлау һәм реконструкцияләү);

- урамнарны яктырту җайланмасы (Сосновый Бор торак пунктында яктырткычлар сатып алу, урам яктырткычларын монтажлау һәм урнаштыру);

- проектлаштыру, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын төзү һәм ремонтлау (Сосновый Бор бистәсендәге суүткәргечне ремонтлау);

-янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (проектны эшләү һәм массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерү, махсус аренда.техника, яшелләндерү).

ӘЙЕ ЮК

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

*Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә* гражданнар җыенында катнашучы **1062** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **689** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **677** кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы **12** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә граждannar җыены карар бирде:

1.Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге "Сосновый Бор поселогы граждannar җыенын узган, граждannar җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2025 елда яшәү урыны буенча Кнәз авыл җирлеге Сосновый Бор поселогы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге граждannar һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория граждannar өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ("Сосновый Бор бистәсендә бистә эчендәге асфальт һәм вак таш белән эшләнгән юлларны ремонтлау һәм реконструкцияләү);

- урамнарны яктырту җайланмасы (Сосновый Бор торак пунктында яктырткычлар сатып алу, урам яктырткычларын монтажлау һәм урнаштыру);

- проектлаштыру, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын төзү һәм ремонтлау (Сосновый Бор бистәсендәге суүткәргечне ремонтлау);

-янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (проектны эшләү һәм массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерү, махсус аренда.техника, яшелләндерү).

3. РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган граждannarны, аларның гаилә әгъзаларын Князево авыл җирлеге территориясендә теркәлгән взнослардан азат итәргә.

4. Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Сосновый Бор поселогы граждannar җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

5. Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Сосновый Бор поселогы граждannar җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Кнәз авыл җирлеге башлыгы И.М.Вилданов